КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 декабрь г.Казань № 1181

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 908 нче карары белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 908 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче; 2016 ел, 18 июнь, 414 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 834 нче; 2018 ел, 30 июль, 618 нче; 2020 ел, 18 май, 402 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

«9. Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итү Министрлыкның (вәкаләтле оешманың) территориаль органы җитәкчесе тарафыннан гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле һәм түбәндәге таблицада күрсәтелгән документлар һәм мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

| Т/с | Документ исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Гариза бирүченең яисә аның законлы вәкиленең шәхесен раслый торган документ (гариза бирүченең вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 2. | Законлы вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (гариза бирүченең вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 3. | Бала туу турында мәгълүматлар (балигъ булмаган затка социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 4. | Татарстан Республикасы территориясендә гариза бирүченең яшәү урыны буенча теркәлү урынын раслый торган мәгълүматлар |
| 5. | Татарстан Республикасы территориясендә гариза бирүченең тору урыны буенча теркәлүен раслый торган мәгълүматлар |
| 6. | Балигъ булган гариза бирүченең вакытлыча эшкә яраклы булуы турында мәгълүматлар (суд тарафыннан вакытлыча эшкә яраклы дип танылган балигъ булган затка социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 7. | Гариза бирүченең эшкә яраксызлыгы турында мәгълүматлар (суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган затка социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 8. | Опека билгеләү турында мәгълүматлар (суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган затка, ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 9. | Попечительлек билгеләү турында мәгълүматлар (суд тарафыннан вакытлыча эшкә яраклы дип танылган балигъ булган затка, 14 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге балигъ булмаган затка һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган затка социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 10. | Индивидуаль шәхси счетның иминият номеры |
| 11. | Гариза бирүченең сәламәтлеге хәле, чит кеше каравына мохтаҗ булу турында медицина оешмасының белешмә кәгазе |
| 12. | Психиатр табиб катнашында табиблар комиссиясе бәяләмәсе (психик бозылышлары булган граждannar өчен билгеләнгән интернат йортта социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 13. | Психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе (психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортында балигъ булмаган затка социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 14. | Психиатр табиб катнашында табиблар комиссиясенең инвалид балада психик бозылышлар булу турында бәяләмәсе (психик бозылышлары булган |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортында балигъ булмаган затка социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 15. | Психиатр табиб катнашында табиблар комиссиясенең социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмасына җибәрү өчен зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр булмау турында бәяләмәсе (социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмасында социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 16. | Инвалидлыкны билгеләү фактын раслый торган белешмә кәгазе (инвалид (инвалид балага) социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 17. | Инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы (инвалидка (инвалид балага) социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 18. | Никахлашу турында мәгълүматлар (никахта торучы граждан социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 19. | Төзәтү учреждениесендә булу турында мәгълүматлар (иректән мәхрүм итү урыннарында булган гариза бирүчегә яки гаилә әгъзасына бирелә) |
| 20. | Гариза бирүченең гаилә әгъзасын сак астына алу турында суд карары (гаилә әгъзасы сак астына алынган очракта) |
| 21. | Гариза бирүченең гаилә әгъзасын мәҗбүри дәвалау турында суд карары (гаилә әгъзасы мәҗбүри дәвалануда булган очракта) |
| 22. | Гариза бирүченең гаилә әгъзасы тулысынча дәүләт тәэминатында булуы турында документ (гаилә әгъзасы тулысынча дәүләт тәэминатында булган очракта) |
| 23. | Соңгы алты ай өчен керемнәр турында мәгълүматлар («Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статья-сындагы 1 өлешендә китерелгән категорияләргә караган гражданнарга бирелми)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин